СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы, Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

---

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**25 февраль 2022 ел** **N 43**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 03 декабрендәге 39 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1."Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 03 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1). 190 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннардан алынган продуктларның ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, әйләнә-тирә мохитне хайваннардан алынган калдыклар белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактик чаралар үткәрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ